# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТАТАР ПАРЕМИОЛОГИЯСЕ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Э.Н.Денмөхәммәтова**

*Казан федераль университеты, Россия, Казан*

В статье рассматриваются вопросы вклада великого ученого К.Насыри в начало татарской паремиологии. Дается описание его трудам, и анализ его работ в контексте современных ученых.

The article discusses the contribution of the great scientist K.Nasyri to the top of the Tatar paremiologii. A description of his work, and the analysis of his works in the context of contemporary scholars.

**Ключевые слова***:* паремия, пословицы и поговорки, наследие, нравоучение, традиции

**Keywords:** Tags: proverbs, proverbs and sayings, heritage, morality, tradition

Күренекле галим, мәгърифәтче Каюм Насыйри татар дөньясына һәм, гомумән, киң җәмәгатьчелеккә күпьяклы эшчәнлеге белән мәгълүм. Аның табигать фәннәре буенча төзелгән дәреслекләре, тел белеменә караган сүзлекләре һәм фәнни хезмәтләре тирән эчтәлеге ягыннан бүгенге көн галимнәрен дә таң калдыра. Төрле фәннәр һәм өлкәләр буенча белгеч булган Каюм Насыйри татар паремиологиясенең дә нигезендә торган дип әйтү хаксыз булмас.

Паремиология - фольклорның кыска жанрлары булган мәкаль һәм әйтемнәр, такмак һәм такмазалар, табышмаклар, тизәйткечләр һ.б. шундыйларны өйрәнә торган фән. Аның объекты булган үз эчләренә тирән мәгънә, халык фәлсәфәсен, үткен фикерләр туплаган халык авыз иҗаты ядкярләре фәннең күп тармакларында эшләүче галимнәрнең игътибарын элек-электән җәлеп итә килгән. Шунлыктан татар халкы да үзенең тел җәүһәрләрен җыйнауга, туплауга зур игътибар бирә. «Татар халык мәкальләрен җыю, аларны өйрәнү, тәртипкә салу һәм бастыру эшләре XIX йөзнең беренче чирекләреннән башланып китә»,—дип белдерә Н.Исәнбәт [1: 48]. Бу өлкәдә И.Березин,

С.Күкләшев, М.Салихов, Ш.Саинов, К.Насыйри, Г.Фәезханов һ.б. күренекле шәхесләр башлап җибәргән эшчәнлекне XX гасырда Х.Бәдигый, Л.Җәләй, Н.Борһанова, Л.Мәхмүтовалар, Х.Ярми, Н.Исәнбәт, Х.Мәхмүтов һ.б. дәвам итә. Галимнәр тарафыннан җыентыкларга тупланган мәкальләр халыкның җор теллелеген, тапкырлыгын, тирән акылын чагылдыручы үрнәкләр генә булып калмыйча, инде фәнни өйрәнү объектына да әверелә баралар. Төрки-татар фольклор әсәре үрнәкләре  М.Мамин, Х.Ярми хезмәтләрендә паремияләрнең тематикасына, төзелешенә, эчтәлегенә игътибар юнәлтелсә, Х.Госман, М.Бакиров хезмәтләрендә мәкальләрнең язма поэзия формалашуга китергән алшартлары да тикшерелә. З.Мәҗитов һәм А.Яхин исә мәкальләргә билгеләмә бирү, аларның структурасы, эчтәлек һәм поэтика мәсьәләләрен өйрәнәләр. Күренекле галим, фольклорчы Н.Исәнбәт исә, татар халык мәкальләрен туплап кына калмыйча, аларны өйрәнүне дә максат итеп куя һәм мәкальләрнең жанр үзенчәлекләренә, шигъри формалашуына, иҗтимагый формация һәм сыйнфый бүленешләрне чагылдыруына аеруча игътибар итә, мәкальләрне лингвистик яктан тикшерүгә беренче омтылыш ясый.  Татар фольклорының афористик жанрларын махсус өйрәнгән галим Х.Ш.Мәхмүтов мәкальләрне башка төр паремия әсәрләре белән рәттән тикшерә, гасырлар дәвамында тәрбия коралы, әхлак саклау ролен башкарган мәкальләрне язылмаган кануннар дип атап, аларның эчтәлеге, килеп чыгышының үзенчәлекләре, яшәеше, фикерне кинаяләп әйтү үзлеге һәм поэтикасын үз хезмәтләрендә яктырта.

Соңгы елларда Каюм Насыйри хезмәтләрендә күрсәтелгән юл буенча, дөнья тарихындагы кебек, татар халкының рухи мәдәнияте тарихын өйрәнүдә, фольклорның кыска жанрларын файдалану мөмкинлеге дә исәпкә алына башлады.  Г.Дәүләтшинның «Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы» хезмәтендә күп кенә мәкальләр тарихи чыганак буларак та яктыртылды һәм, татар халкының яшәешен, фәлсәфи карашларын чагылдырып, үткәнебезне күзалларга ярдәмче вазифасын үтәде [2]. Халык фәлсәфәсенә, уй-кичерешләренә төшенү өчен, аларның ни рәвешле, нинди калыпка төрелеп әйтелүләренә дә игътибар итү зарурлыгана басым ясалды һәм  күренекле мәгърифәтче К.Насыйри

фикерләренең  хаклыгы кабат инандырды. Чыннан да, зирәк акыллы, тапкыр бабаларыбыз хисләрен турыдан-туры ярып салырга ашыкмаганнар,  ә кинаяле, читләтеп әйтелгән фикернең тәэсире көчлерәк булуын яхшы аңлаганнар. Алар сүзнең тылсым көченнән, кирәкле йогынтысыннан бик белеп, урынлы файдаланганнар.

Үзеннең төп бурычларының берсе  -  татар халкын агарту, мәгърифәтле итү дип санаган К.Насыйри  педагоглык өлкәсендә дә зур эш башкара. Ул балаларга әхлак тәрбиясе бирүдә  халык авыз иҗаты әсәрләре зур роль уйнавына игътибар итә, һәм  баланың сөйләм телен үстерү,  туган телен һәм аның мантыкый төзелешен өйрәтүдә,  мәдәни мирасы белән таныштыруда фольклор материалларының алыштыргысыз булуын раслый.  Шунлыктан галим балаларга тәрбия бирүгә багышланган һәр хезмәтендә мәкаль һәм әйтемнәргә, табышмак һәм кыска җырларга урын бирә, алар аша халык  фикерен яшь буынга җиткерә.

Каюм Насыйриның "Әхлак исаләсе", "Тәрбия", "Балаларга тәгълим бирмәк", "Китап - эт тәрбия" хезмәтләрендәге  халык авыз иҗаты әсәрләре, галимнең үзе тарафыннан җыелып, лингвистик яктан эшкәртелеп биреләләр. Мәгърифәтче хикәятләрен туры сүзле мәкаль белән йомгакларга ярата һәм сүзнең тылсымлы көченә чын күңелдән ышана. Мәсәлән, ул: "Сүз бозау имезер. Бер хикаяткә ишарәттер. Күп сүзгә кереп китеп, эшеңне онытма, димәктер"- дип яза. [3: 141].

Мәгърифәтче гореф-гадәтләрне саклауга  милләтне саклау буларак карый. Бу хакта  еллык календарьларында кабат-кабат яза.  Әлеге гамәлләрдә борынгы мифик образларның  онытылмавы да мөһим булуын билгели.  Ул: " Ислам кабул ителүдән күп еллар элек татарның үз хыялында туган үзләреннән-үзләре татарлыкны күрсәтеп тора торган су иясе, убыр, бичура, албасты, ялмавыз, шүрәле"  кебек мифик затларны әкиятләр, ырымнар, табышмаклар һ.б. аша яшь буынга милли тәрбия бирүдә файдаланырга өнди [3: 128]. Үзе дә  балалар уен фольклорын җыюга, аны популярлаштыруга зур көч куя. Ул җыйган бишек

җырлары, мавыктыргычлар, эндәшләр һәм такмазалар “Татар халык авыз иҗаты” сериясендә басылган балалар фольклоры томына кертелгәннәр [4].

К.Насыйри кинаяләп әйтүнең турыдан әйтелгәнгә караганда үтемлерәк булуын да онытмый. Изге Коръәндә әйтелгән “бишектән ләхеткәчә белем ал” шигаре Каюм Насыйриның да тормыш девизына әверелә. Ул белем алуны яшьтән башларга кирәклеген ассызыклый, шунлыктан нәкъ менә кече яшьтәгеләргә кызыклы булган вакыйгалар аша “сабак бирә”.

Галим теоретик белемне гамәли тәҗрибәләр белән ныгытырга чакыра. Акыл тәҗрибә булганда гына кыйммәткә ия булуына басым ясап, аларның бер-берсеннән җир белән су кебек аерылгысызлыгын ассызыклый, тапкыр сүзләр аша бу фикерне укучыларына җиткерә.

К.Насыйри татар паремиологиясендә урын алган олыларны хөрмәтләү, ялган һәм начар гадәтләрне тәнкыйтьләү, тырышлыкны зурлау, хезмәт аша байлыкка ирешү кебек һ.б. төп фикерләрне һәр әсәрендә, дәреслекләрендә алга сөрә. Халык фикере аша халыкны тәрбияли. Шул гамәлләре аша да ул онытылмас, халык күңелендә сакланыр.

**Әдәбият**


1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. – Казан: Татар.китап нәшр.,1959. Т.1. , 229 б.
2. Дәүләтшин Г. М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. – Казан: Татар. китап. нәшр, 1999. 117 б.
3. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1974. 1 т., 148 б.
4. 4. Татар халык авыз иҗаты. Балалар фольклоры. – Казан: Татар. китап. нәшр, 1993. 336 б.